## Мәктәп исеме

***"Арча 6нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе"***

## 1. Чараның исеме

" Нәүрүз бәйрәме "

## 2. Чараның  дәрәҗәсе (мәктәп, районкүләм, республика)

Мәктәп

## 3. Уткәрү вакыты

20.03.2021

## 4. Катнашучылар саны

57

## 5. Чараның кыскача эчтәлеге

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында мәктәптә Нәүрүз бәйрәме узды.
Нәүрүз – татар халкының иң матур йола бәйрәмнәреннән берсе, ул 21 мартта көн белән төн тигезләшкән көнгә туры килә. Нәүрүз – фарсыча “яңа көн” дигәнне аңлата, икенче төрле язгы Яңа ел, дип тә әйтәләр. Бу көнне кешеләр кунак чакыралар, җырлыйлар һәм бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар, уеннар уйныйлар. Бүген мәктәбебездә  Нәүрүз бәйрәме гөрләп узды. Кыш бабай белән Нәүрүзбикә “көч сынаштылар”: аркан тартыштылар, табышмаклар әйттеләр, биеделәр, кашыкка йомырка салып йөгерделәр. Әмма яз кызының көче күбрәк иде - ул җиңде. Кыш бабай биреште, тик үпкәләмәде. Балалар халык уеннарын: “Түбәтәй”, “Йомырка куйган кашык тотып йөгерү”, санамышлар әйтү, табышмакларга җавап табуда өлгерлек күрсәттеләр, яз һәм Нәүрүз турында җырлар, шигырьләр башкардылар. Фольклор бәйрәмнәрен уздыру балаларыбызда телебезгә карата мәхәббәт хисләре, әхлак тәрбисе уятырга ярдәм итә, борынгы гореф-гадәтләрне онытмаска өйрәтә.

## 6. Сайтта, соц. челтәрләрдә чараны чагылдырган сылтама

Место для ввода текста.

## 7. СМИ

Место для ввода текста.

## 8. СМИ


